ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

17.05.2019 ел Баулы шәһәре №141

«Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында мәктәпкәчә төп гомуми белем бирү программасын тормышка ашыручы белем бирү оешмаларына (балалар бакчаларына) балаларны исәпкә кую һәм кабул итү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендә кабул ителгән №210-ФЗ Федераль закон, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Мәктәпкәчә теп гомуми белем бирү программасын тормышка ашыручы белем бирү оешмаларына (балалар бакчаларына) балаларны исәпкә кую һәм кабул итү” муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының (Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2015 елның 10 мартындагы 1389/15 номерлы боерыгы белән расланган) якынча формасына үзгәрешләр кертү турында” 2018 елның 26 декабрендә кабул ителгән 1975/18 номерлы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Кушымтадагы «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында мәктәпкәчә төп гомуми белем бирү программасын тормышка ашыручы белем бирү оешмаларына (балалар бакчаларына) балаларны исәпкә кую һәм кабул итү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын расларга.

2. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең "Балаларны мәктәпкәчә төп белем бирү программасын тормышка ашыручы муниципаль белем бирү учреждениеләренә (балалар бакчаларына) кертүгә һәм путевка алуга чиратта торучылар исемлегенә кертү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ регламентын раслау турында" 2013 елның 18 июлендә кабул ителгән 176нчы карары һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма

комитетының 2016 елның 30 июнендә кабул ителгән "Мәктәпкәчә белем бирү буенча төп белем бирү программасын гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирү оешмаларына (балалар бакчаларына) чиратта торучылар исемлегенә кертү һәм юллама бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" 209нчы карары үз кечен югалткан дип санарга.

3. "Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының мәгариф бүлеге" МКУны Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында балаларны мәктәпкәчә төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларына (балалар бакчаларына) исәпкә кую һәм кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү буенча вәкаләтле орган итеп билгеләргә.

4. Мәктәпкәчә төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы Баулы муниципаль районы мәгариф оешмалары җитәкчеләренә әлеге карарны ата-аналар укырлык урыннарда урнаштырырга.

5. Әлеге карарны http://www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының http://www.bavly.tatarstan.ru сайтында бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы — И.И. Хөснуллина